**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет
Тойкинского сельского
поселения Азнакаевского
муниципального района**

ул. Джалиля , д. 19, село Тойкино,
Азнакаевского муниципального района, 423302
Тел. (факс) 45-0-89

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы
Туйкә авыл җирлеге
башкарма комитеты**

Җәлил урамы,19, Туйкә авылы
Азнакай муниципаль районы, 423302
Тел. (факс) 45-0-89

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 август 2017 ел. № 13

Җирлекнең социаль-икътисадый үсеше фаразын эшләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 173 статьясына таянып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Туйкә авыл җирлеге Уставына таянып, муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш фаразы параметрларын формалаштыру процессында катнашучылар арасында үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру максатында,

Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге
Башкарма комитеты карар кабул итте:

1. Җирлекнең социаль-икътисадый үсеше фаразын эшләү тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башлык Закирова Р.Р.